**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 4 маендагы 1525 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 11 сентябрендәге 3856 номерлы**
**«2024 – 2026 елларга Казан шәһәренең авария хәлендәге**
**торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча**
**муниципаль адреслы программаны раслау турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәренең авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны финанслау күләмнәрен төгәлләштерүгә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 11 сентябрендәге 3856 номерлы «2024 – 2026 елларга Казан шәһәренең авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 28 декабрендәге 5483 номерлы, 2025 елның 4 февралендәге 240 номерлы һәм 2025 елның 17 октябрендәге 3576 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. исемендә, преамбулада, 1 пунктта «2024-2026 елларга» сүзләрен «2024-2027 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.1. «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе акчалары һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына Программаны гамәлгә ашыру өчен Министрлыктан Казан шәһәре бюджетына 1 376 206 524,58 сум күләмендә (шул исәптән 2024 елда – 72 634 474,47 сум, 2025 елда – 201 064 452,89 сум, 2026 елда – 1 102 507 597,22 сум) акча керүне тәэмин итәргә»;

1.3. 2.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсенә Программаны гамәлгә ашыру кысаларында, «Территорияләрне үстерү фонды»

гавами-хокукый компаниясе акчалары, Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән финанс ярдәме, Казан шәһәре Башкарма комитетының резерв фонды акчалары хисабыннан 1 390 260 817,75 сум (2024 елда – 73 368 156,03 сум, 2025 елда – 203 095 406,96 сум, 2026 елда – 1 113 797 254,76 сум) күләмендә акча бүлеп бирергә, шул исәптән:

2.2.1. билгеләнгән тәртиптә торак урыннар сатып алу өчен 1 281 075 592,79 сум, шуларның 476 559 723,57 сумы – «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе акчалары хисабыннан (2024 елда – 59 428 206,38 сум, 2025 елда – 89 649 770,47 сум, 2026 елда – 327 481 746,72 сум), 791 705 113,27 сумы – Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән финанс ярдәме хисабыннан (2024 елда – 13 206 268,09 сум, 2025 елда – 111 414 682,42 сум, 2026 елда – 667 084 162,76 сум), 12 810 755,95 сумы – Казан шәһәре Башкарма комитетының резерв фонды акчалары хисабыннан (2024 елда – 733 681,56 сум, 2025 елда – 2 030 954,07 сум, 2026 елда – 10 046 120,32 сум);

2.2.2. 2026 елда сатып алу юлы белән милекчеләрдән җир кишәрлекләрен һәм торак урыннарны билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри алу өчен 109 185 224,96 сум, шуларның 107 941 687,74 сумы – Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән финанс ярдәме хисабыннан, 1 243 537,22 сумы – Казан шәһәре Башкарма комитетының резерв фонды акчалары хисабыннан»;

1.4. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына (Г.Р.Минһаҗева) Казан шәһәренең капиталь чыгымнар программаларында ел саен 2024-2027 елларга Программаны гамәлгә ашыруга 1 390 260 817,75 сум (2024 елда – 72 634 474,47 сум, 2025 елда – 201 064 452,89 сум, 2026 елда – 1 102 507 597,22 сум) күләмендә, шул исәптән «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе акчасы хисабыннан – 476 559 723,57 сум (2024 елда – 59 428 206,38 сум, 2025 елда – 89 649 770,47 сум, 2026 елда – 327 481 746,72 сум), Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән финанс ярдәме акчалары хисабыннан – 899 646 801,01 сум (2024 елда – 13 206 268,09 сум, 2025 елда – 111 414 682,42 сум, 2026 елда – 775 025 850,50 сум), Казан шәһәре Башкарма комитетының резерв фонды акчалары хисабыннан 14 054 293,17 сум (2024 елда – 733 681,56 сум, 2025 елда – 2 030 954,07 сум, 2026 елда – 11 289 657,54 сум) күләмендә чыгымнарны кертергә»;

1.5. 4 пунктта «2025 елның 1 февраленә кадәр» сүзләрен «ел саен хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. карарга кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.7. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 11 сентябрендәге 3856 номерлы карарына кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 4 маендагы
1525 номерлы карарына
кушымта

# 2024 – 2027 елларга Казан шәһәренең авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программа

## Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | 2024 – 2027 елларга Казан шәһәренең авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программа (алга таба – Программа) |
| Муниципаль заказчы – Программаның координаторы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе |
| Программаны төп эшләүче | Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре |
| Программаның төп чараларын башкаручылар | Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты |
| Программаның төп максатлары һәм бурычлары | Программаның максаты – гражданнарны билгеләнгән тәртиптә [2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фонды турында»гы федераль закон (алга таба – 185-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә] авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге күпфатирлы йортлардан күчерүне финанс һәм оештыру ягыннан тәэмин итү.<br>Бурыч – Казан шәһәренең авария хәлендә һәм яшәү өчен яраксыз дип танылган торак фондыннан гражданнарны күчерү (185-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә) |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты | 2024 – 2027 еллар, шул исәптән:<br>- 2024 ел этабы – 2024 елның 31 декабренә кадәр;<br>- 2025 ел этабы – 2026 елның 31 декабренә кадәр;<br>- 2026 ел этабы – 2027 елның 31 декабренә кадәр |

| | |
|---|---|
| Программаны финаслауның күләме һәм чыганаклары | Программаны финанслау түбәндәге акчалар хисабына башкарыла:<br>- «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе (алга таба – Фонд) – 476 559 723,57 сум күләмендә;<br>- Татарстан Республикасы бюджеты – 899 646 801,01 сум күләмендә;<br>- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 14 054 293,17 сум күләмендә.<br>Программаны финанслауның гомуми күләме – 1 390 260 817,75 сум |
| Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | 2024-2027 елларда Программаны үтәү нәтиҗәсендә халыкны күчерү һәм авария хәлендәге биналарны бушату.<br>Төп чараларның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары Программага 1 номерлы кушымтада китерелде.<br>Программаны үтәүнең, шул исәптән еллар буенча үтәүнең, планлаштырыла торган күрсәткечләре Программага 6 номерлы кушымтада китерелде |

## I. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысуллары белән хәл итү зарурлыгын нигезләү

Татарстан Республикасында һәм Казан шәһәрендә дәүләт торак сәясәте буенча торак өлкәсенең тотрыклы эшләвенә һәм аны үстерүгә кучү проблемасын комплекслы хәл итүгә юнәлдерелгән, гражданнар өчен торак алу мөмкинлеген, анда имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итә торган бурычларының берсе – авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшыртуга хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итү.

Программа «Яшәү өчен инфраструктура» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында һәм 185-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә эшләнде.

Программада авария хәлендәге торак фонды дигәндә 2017 елның 1 гыйнварыннан соң эксплуатацияләү барышында физик яктан тузу белән бәйле рәвештә билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип танылган һәм түбәндәгечә күчерү планлаштырыла торган күпфатирлы йортлардагы торак урыннар җыелмасы аңлашыла:

- 2024 ел этабы буенча – Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджеттан финанслауда катнаша торган акчаларны исәпкә алып, Фондның 2019-2023 елларга Татарстан Республикасы өчен билгеләнгән финанс ярдәме лимитларының файдаланылмаган чараларының тотылмый калган өлеше кысаларында;

- 2025 ел этабы буенча – Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджеттан финанслауда катнаша торган акчаларны исәпкә алып, 2025-2027 елларга Фондның бүлеп бирелгән финанс ярдәме лимитлары кысаларында.

Хәзерге вакытта авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарның күбесе билгеләнгән таләпләргә туры килә торган торак урыннарны мөстәкыйль рәвештә сатып ала алмый.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарны күчерү өчен җитәрлек күләмдә акча булмау әлеге гражданнарны торак урыннар белән тәэмин итү проблемасын хәл итүдә каршылык тудыра.

Программаны гамәлгә ашыру кысаларында авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү өчен бүлеп бирелә торган Фонд акчалары һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына тиешле финанс ярдәме күрсәтелгәндә, әлеге проблема хәл ителергә мөмкин.

## II. Программаның төп максатлары, бурычлары һәм аны гамәлгә ашыру вакыты

Программаның төп максаты – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Фонд акчалары хисабына финанс ярдәме күрсәтүнең 185-ФЗ номерлы федераль закон белән билгеләнгән шартларын үтәүне тәэмин иткән очракта, билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге күпфатирлы йортлардан гражданнарны күчерүне финанс һәм оештыру ягыннан тәэмин итү.

Куелган максатка ирешү өчен гражданнарны Казан шәһәренең авария хәлендә һәм яшәү өчен яраксыз дип танылган торак фондыннан күчерү мәсьәләсен хәл итү күздә тотыла.

Файдалану барышында физик яктан тузу сәбәпле 2017 елның 1 гыйнварыннан соң билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип танылган, Программаны гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарны күчерү өчен финанс ярдәме күрсәтү планлаштырыла торган күпфатирлы йортлар исемлеге Программага 2 һәм 2.1 номерлы кушымталарда китерелә.

Программа 2024 елдан 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлгә ашырылачак.

Программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары Программага 1 номерлы кушымтада китерелде.

Программа үтәлешенең этаплар буенча планлаштырылган күрсәткечләре Программага 6 номерлы кушымтада бирелде.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү чараларын гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары Фонд, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына формалаштырыла. Программаны гамәлгә ашыруга гомуми чыгымнар барлык финанслау чыганаклары хисабына 1 390 260 817,75 сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

- Фонд – 476 559 723,57 сум (34,3%);
- Татарстан Республикасы бюджеты – 899 646 801,01 сум (64,7%);
- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 14 054 293,17 сум (1%).

2024 ел этабы буенча – 73 368 156,03 сум, шул исәптән:

- Фонд – 59 428 206,38 сум (81%);
- Татарстан Республикасы бюджеты – 13 206 268,09 сум (18%);
- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 733 681,56 сум (1%).

2025 ел этабы буенча – 203 095 406,96 сум, шул исәптән:

- Фонд – 89 649 770,47 сум (44,1%);
- Татарстан Республикасы бюджеты – 111 414 682,42 сум (54,9%);
- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 2 030 954,07 сум (1%).

2026 ел этабы буенча – 1 113 797 254,76 сум, шул исәптән:

- Фонд – 327 481 746,72 сум (29,4%);
- Татарстан Республикасы бюджеты – 775 025 850,50 сум (69,6%);
- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты – 11 289 657,54 сум (1%).

Программаны финанслау чаралары күләме Программага кертелгән һәм файдалану барышында физик яктан тузу сәбәпле авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип танылган күпфатирлы йортлар исемлегеннән, гражданнарга бирелә торган торак урыннарның гомуми мәйданының бер квадрат метрына планлаштырыла торган бәя күләменнән һәм Программага кертелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортларда гражданнар (юридик затлар) милкендә булган алына торган торак урыннарның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен планлаштырыла торган түләп алу бәясе күләменнән, шулай ук гражданнарны Программага 3 номерлы кушымтада китерелгән күчерү ысулларыннан чыгып билгеләнә.

Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә финанс ярдәме чараларын бүлү Программага 4 номерлы кушымтада китерелде.

Казан шәһәрендә авария хәлендәге торак фондының торак урыннары милекчеләренә башка төзекләндерелгән торак урыннары бирү турындагы суд практикасын исәпкә алып, шулай ук Казан шәһәрендә авария хәлендәге торакны милекчеләрдән сатып алу бәясе югары булуны исәпкә алып, Казан шәһәренең бюджет акчаларын экономияләү максатыннан авария хәлендәге торак милекчеләренә аларның ризалыгы буенча, яклар белән килештереп, алына торган торак урыннар бәясен каплау күләмен билгеләгәндә, аларның бәясен исәпкә алып, башка төзекләндерелгән торак урыннар бирү планлаштырыла.

Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясы нигезендә, шулай ук законлы көченә кергән суд актлары нигезендә авария хәлендәге торак фондының торак урыннары милекчеләренә алына торган торакка алмашка уңайлыклары булган торак урыннар авария хәлендәге йортта урнашкан алына торган торак урын бәясе күләмен кайтару хисабына бирелә.

Сатып алына торган торак урыннарга карата тәкъдим ителә торган таләпләр Программага 5 номерлы кушымтада китерелде.

Авария хәлендәге торак фондындагы торак урыннарны наемга алучыларга торак урыннар Россия Федерациясе Торак кодексының 89 статьясы нигезендә бирелә.

Фонд, Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджет акчалары хисабына алынган чаралар түбәндәгеләр өчен генә тотыла:

- күпфатирлы йортларда, шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән блоклап төзелгән йортларда (шул исәптән төзелеш тәмамланмаган күпфатирлы йортларда) торак урыннар сатып алуга һәм мондый йортларны төзүгә (мондый йортларны төзү максатыннан проект документларын әзерләүне дә кертеп), торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый яктан җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган методика нигезендә сайлап алынган проектлар буенча шәхси торак йортлар төзүгә, шулай ук мондый шәхси торак йортлар сатып алуга, шул исәптән торак урыннарны алга таба гражданнарга социаль наем шартнамәсе буенча бирү, яки социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәсе буенча, яки авария хәлендәге торак фондыннан күчерү белән бәйле рәвештә маневр фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәсе буенча, яки


ЕМСЭД

авария хәлендәге торак фонды торак урынының хуҗасы белән алмаштыру шартнамәсе буенча алуга;

- авария хәлендәге торак фондына керүче торак урыннары булган гражданнарга Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 7 өлеше нигезендә алынган торак урыннар өчен түләүгә.

## III. Программа чараларын гамәлгә ашыру механизмы, Программа белән идарә итүне оештыру һәм аны гамәлгә ашыруны контрольдә тоту

Муниципаль заказчы – Программа координаторы Программаны гамәлгә ашыру барышына гомуми җитәкчелек итә һәм аны контрольдә тота, планлаштыруны, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык), Программаны башкаручылар белән үзара хезмәттәшлекне оештыра.

Программаны башкаручылар түбәндәгеләрне тәэмин итә:

- Программаны эшләүне, раслауны һәм аңа үзгәрешләр кертүне;

- 185-ФЗ номерлы федераль законның 20.14 статьясы белән каралган финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне;

- гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә юнәлдерелгән акчаларны тоту турындагы хисапны алып баруны һәм аны Программаның дәүләт заказчысына тапшыруны;

- гражданнарны авария хәлендә дип танылган торак фондыннан күчерү сәбәпле, яллап торучылар белән социаль наем шартнамәләре һәм торак милекчеләре белән шартнамәләр буенча торак урыннар бирүне;

- күпфатирлы йортлар төзелгән очракта, гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен алдан билгеләнгән йортлар төзелешенә проект документларын эшләүне;

- сатулар үткәрүне һәм күпфатирлы йортлар (блоклап төзелгән йортлар) төзүгә, торак урыннар сатып алуга муниципаль контрактлар, торак урыннарны сатып алуга шартнамәләр төзүне;

- гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерүгә юнәлдерелгән бюджет акчаларын файдалануны контрольдә тотуны;

- бушатылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итүне.

Программаны башкаручылар Программа чараларын гамәлгә ашыру, аларның ахыргы нәтиҗәләре, бүлеп бирелә торган финанс чараларын максатчан куллану өчен җаваплы, муниципаль заказчыга – Программа координаторына

чараларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тапшыралар.

Муниципаль заказчы билгеләнгән вакытта Министрлыкка, шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Программаны гамәлгә ашыру барышы һәм финанс чараларын тоту турында хисап тапшыра.

## V. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү

185-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге күпфатирлы йортлардан гражданнарны уңышлы (тулысынча) күчерү Программаның нәтиҗәлелеге күрсәткече булып тора.

Нәтиҗәлелекнең планлаштырыла торган күрсәткечләре Программага 6 номерлы кушымтада китерелде.

Программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәчәк:

- гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларына хокукларын гамәлгә ашыруны;
- билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип танылган күпфатирлы йортларда яшәүчеләрнең санын киметүне;
- җәмгыятьтә социаль киеренкелекне киметүне;
- авария хәлендәге торак фондын бетерү хисабына Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең тышкы күренешен яхшыртуны.

2024 – 2027 елларга Казан шәһәренең
авария хәлендәге торак фондыннан
гражданнарны күчерү буенча
муниципаль адреслы программага
1 номерлы кушымта

**2024 – 2027 елларга Казан шәһәренең авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары**

| Программаны үтәү күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Программаны үтәү нәтиҗәсендә ирешелгән |
|---|---|---|
| 2024-2027 елларга Казан шәһәренең авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны (алга таба – Программа) үтәү нәтиҗәсендә күчерелгән кешеләр саны | Кеше | 574 |
| Программага кертелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортларда теркәлгән кешеләрнең гомуми санынннан Программаны үтәү кысаларында күчерелгән кешеләр өлеше | Процент | 100 |
| Программаны үтәү кысаларында яшәүчеләре күчерелгән торак урыннар саны | Данә | 237 |
| Программаны үтәү кысаларында яшәүчеләре күчерелгән авария хәлендәге күпфатирлы йортларның өлеше | Процент | 100 |
| Программаны гамәлгә ашыру кысаларында аерым торак һәм торак булмаган урыннар буенча бушаган бүлмәләрнең гомуми саны (наемга алу, сатып алу һәм алмашу буенча барлыгы, берәмлекләрдә һәм квадрат метрларда) | Данә | Гомуми мәйданы 6348,98 кв.м булган 237 торак урын |
| «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясенең Программаны үтәү өчен Татарстан Республикасына карата торган акчалары лимитыннан тотылган акчалар өлеше | Процент | 100 |

2024-2027 елларга Казан шәһәренең авария хәлендәге торак фондыннан
гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага 2
номерлы кушымта
.

# Авария хәлендәге күпфатирлы йортлар исемлеге

| № т/б | Күпфатирлы йорт адресы | Мәдәни мирас объекты булып торамы (әйе/юк) | Файдалануга тапшыру елы | Авария хәлендә дип тану датасы | Күчерелергә тиешле торак фонды турында мәгълүмат | | | Гражданнар-ны күчерүне тәмамлау планлашты-рыла торган дата | Йорт урнашкан урында җир кишәрлеген формалаштыру турында мәгълүмат | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | җир кишәрлеге мәйданы | җир кишәрлегенең кадастр номеры | җир кишәрлегенә характеристика (бер йорт торган урында формалаштырылган, формалаштырылмаган) |
| | | | ел | дата | мәйданы, кв.м | кеше саны | гаиләләр саны | дата | кв.м | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| **Фонд акчалары хисабына финанслау каралган 2024-2027 елларда күчерү программасы буенча, шул исәптән:** | | X | X | X | 6 348,98 | 574 | 237 | X | 17 789,90 | X | X |
| 1 | Казан шәһәре, Адмиралтейство урамы, 13/30 йорт | Юк | 1933 | 02.07.2018 | 1 228,10 | 127 | 61 | 31.12.2027 | 2 764,00 | 16:50:090104:34 | Бер йорт астында формалаштырылган |
| 2 | Казан шәһәре, Баженов урамы, 28 йорт | Юк | 1958 | 03.09.2018 | 587,20 | 48 | 15 | 31.12.2027 | 1 776,00 | 16:50:090569:54 | Бер йорт астында формалаштырылган |
| 3 | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | Юк | 1936 | 29.05.2017 | 577,10 | 34 | 16 | 31.12.2026 | 3 043,00 | 16:50:280845:382 | Бер йорт астында формалаштырылган |
| 4 | Казан шәһәре, Гавана урамы, 75 йорт | Юк | 1961 | 25.04.2018 | 242,00 | 15 | 7 | 31.12.2024 | 796,00 | 16:50:280807:18 | Бер йорт астында формалаштырылган |
| 5 | Казан шәһәре, Гладилов урамы, 56 йорт | Юк | 1950 | 23.05.2018 | 724,20 | 81 | 31 | 31.12.2027 | 1 350,50 | 16:50:090560:6 | Бер йорт астында формалаштырылган |
| 6 | Казан шәһәре, Димитров урамы, 15 йорт | Юк | 1952 | 03.09.2018 | 422,40 | 22 | 12 | 31.12.2027 | 336,40 | 16:50:090436:15 | Формалаштырылмаган |
| 7 | Казан шәһәре, Дружный тыкрыгы, 9 йорт | Юк | 1980 | 27.09.2017 | 25,50 | 1 | 1 | 31.12.2026 | X | X | Формалаштырылмаган |
| 8 | Казан шәһәре, Дружный тыкрыгы, 28 йорт | Юк | 1980 | 02.04.2018 | 46,30 | 5 | 1 | 31.12.2024 | X | X | Формалаштырылмаган |
| 9 | Казан шәһәре, Дружный тыкрыгы, 34а йорт | Юк | 1980 | 02.04.2018 | 40,80 | 4 | 1 | 31.12.2024 | X | X | Формалаштырылмаган |
| 10 | Казан шәһәре, Тимерьюлчылар урамы, 9 йорт | Юк | 1937 | 03.09.2018 | 464,40 | 29 | 10 | 31.12.2027 | 1 578,00 | 16:50:280845:380 | Бер йорт астында формалаштырылган |
| 11 | Казан шәһәре, Каспий урамы, 8 йорт | Юк | 1956 | 30.12.2021 | 348,40 | 31 | 13 | 31.12.2027 | 794,00 | 16:50:050130:337 | Бер йорт астында формалаштырылган |
| 12 | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | Юк | 1931 | 27.09.2017 | 490,46 | 57 | 22 | 31.12.2026 | 1 082,00 | 16:50:090110:176 | Бер йорт астында формалаштырылган |
| 13 | Казан шәһәре, Окраинная урамы, 8 йорт | Юк | 1953 | 22.06.2018 | 329,82 | 29 | 13 | 31.12.2027 | 660,00 | 16:50:280845:5 | Бер йорт астында формалаштырылган |
| 14 | Казан шәһәре, Степан Халтурин урамы, 7 йорт | Юк | 1917 | 28.03.2019 | 576,70 | 55 | 26 | 31.12.2027 | 1 679,00 | 16:50:090440:366 | Бер йорт астында формалаштырылган |
| 15 | Казан шәһәре, Юбилей урамы, 3 йорт | Юк | 1962 | 10.03.2017 | 245,60 | 36 | 8 | 31.12.2024 | 1 931,00 | 16:50:000000:7292 | Бер йорт астында формалаштырылган |

2024-2027 елларга Казан шәһәренең авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага 2.1 номерлы кушымта

**Файдалану барышында физик яктан тузу сәбәпле билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип танылган күпфатирлы йортлар исемлеге (торак урыннар буенча)**

| № т/б | Муниципаль берәмлек атамасы | Күпфатирлы йорт адресы | Торак урын номеры | Күчерелергә тиешле авария хәлендәге торак фонды турында белешмәләр | | | Этап | Торак урынның милек тибы | Төбәк программасы атамасы һәм реквизитлары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | мәйданы, кв.м | кеше саны | гаиләләр саны | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 10 | 9 |
| **Барлыгы** | | | | **6 348,98** | **574** | **237** | **х** | **х** | **х** |
| **Казан шәһәре буенча барлыгы, Дружный тыкрыгы, 28 йорт** | | | | **46,30** | **5** | **1** | **х** | **х** | **х** |
| 1 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Дружный тыкрыгы, 28 йорт | 3 | 46,30 | 5 | 1 | 2024 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| **Казан шәһәре буенча барлыгы, Дружный тыкрыгы, 34а йорт** | | | | **40,80** | **4** | **1** | **х** | **х** | **х** |
| 1 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Дружный тыкрыгы, 4а йорт | 4 | 40,80 | 4 | 1 | 2024 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| **Казан шәһәре буенча барлыгы, Гавана урамы, 75 йорт** | | | | **242,00** | **15** | **7** | **х** | **х** | **х** |
| 1 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Гавана урамы, 75 йорт | 1 | 32,40 | 2 | 1 | 2024 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 2 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Гавана урамы, 75 йорт | 3 | 37,50 | 2 | 1 | 2024 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 3 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Гавана урамы, 75 йорт | 4 | 32,20 | 3 | 1 | 2024 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 4 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Гавана урамы, 75 йорт | 5 | 31,80 | 2 | 1 | 2024 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 5 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Гавана урамы, 75 йорт | 6 | 38,70 | 3 | 1 | 2024 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 6 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Гавана урамы, 75 йорт | 7 | 38,20 | 2 | 1 | 2024 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 7 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Гавана урамы, 75 йорт | 8 | 31,20 | 1 | 1 | 2024 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| **Казан шәһәре буенча барлыгы, Юбилей урамы, 3 йорт** | | | | **245,60** | **36** | **8** | **х** | **х** | **х** |
| 1 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Юбилей урамы, 3 йорт | 1 | 27,00 | 10 | 1 | 2024 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 2 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Юбилей урамы, 3 йорт | 2 | 29,80 | 1 | 1 | 2024 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 3 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Юбилей урамы, 3 йорт | 3 | 31,00 | 7 | 1 | 2024 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 4 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Юбилей урамы, 3 йорт | 4 | 31,90 | 2 | 1 | 2024 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 5 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Юбилей урамы, 3 йорт | 5 | 33,70 | 3 | 1 | 2024 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 6 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Юбилей урамы, 3 йорт | 6 | 30,40 | 5 | 1 | 2024 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 7 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Юбилей урамы, 3 йорт | 7 | 31,60 | 4 | 1 | 2024 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 8 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Юбилей урамы, 3 йорт | 8 | 30,20 | 4 | 1 | 2024 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| **Казан шәһәре буенча барлыгы, Бирюзовая урамы, 12 йорт** | | | | **577,10** | **34** | **16** | **х** | **х** | **х** |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 1 | 31,20 | 1 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 2 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 2, 1 нче бүлмә | 12,20 | 2 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 3 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 2, 2 нче бүлмә | 16,30 | 1 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 4 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 3 | 48,10 | 2 | 1 | 2025 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 5 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 4 | 31,90 | 1 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 6 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 5 | 30,50 | 3 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 7 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 6 | 38,70 | 1 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 8 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 7 | 50,50 | 4 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 9 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 8 | 32,30 | 3 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 10 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 10 | 47,40 | 2 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 11 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 11 | 55,80 | 2 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 12 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 12 | 31,50 | 3 | 1 | 2025 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 13 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 13 | 32,00 | 1 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 14 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 14 | 47,50 | 4 | 1 | 2025 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 15 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 15 | 39,30 | 3 | 1 | 2025 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 16 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Бирюзовая урамы, 12 йорт | 16 | 31,90 | 1 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| **Казан шәһәре буенча барлыгы, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт** | | | | **490,46** | **57** | **22** | **x** | **x** | **x** |
| 1 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 1а | 17,10 | 3 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 2 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 1 | 9,00 | 1 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 3 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 3 | 20,90 | 3 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 4 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 6 | 39,00 | 3 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 5 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 7 | 37,20 | 5 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 6 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 9 | 23,90 | 6 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 7 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 10 | 25,80 | 2 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 8 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 11 | 12,40 | 3 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 9 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 12 | 21,40 | 1 | 1 | 2025 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 10 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 13 | 12,90 | 2 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 11 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 14 | 19,40 | 3 | 1 | 2025 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 16, 1 нче бүлмә | 15,20 | 2 | 1 | 2025 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 13 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 16, 2 нче бүлмә | 18,00 | 4 | 1 | 2025 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 14 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 17 | 51,76 | 2 | 1 | 2025 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 15 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 18 | 22,20 | 7 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 16 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 19, 1 нче бүлмә | 16,30 | 1 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 17 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 20 | 15,00 | 1 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 18 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 21 | 17,70 | 1 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 19 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 22 | 14,00 | 1 | 1 | 2025 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 20 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 23 | 19,50 | 1 | 1 | 2025 | Шәхси милек (физик зат) | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 21 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 25 | 38,40 | 3 | 1 | 2025 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| 22 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Клара Цеткин урамы, 17Б йорт | 26 | 23,40 | 2 | 1 | 2025 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| **Казан шәһәре буенча барлыгы, Дружный тыкрыгы, 9 йорт** | | | | **25,50** | **1** | **1** | **х** | **х** | **х** |
| 1 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Дружный тыкрыгы, 9 йорт | 2 | 25,50 | 1 | 1 | 2025 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Территорияләрне үстерү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
| **Казан шәһәре буенча барлыгы, Адмиралтейство урамы, 13/30 йорт** | | | | **1 228,10** | **127** | **61** | **х** | **х** | **х** |
| 1 | Казан шәһәре | Казан шәһәре, Адмиралтейство урамы, 13/30 йорт | 1а | 28,50 | 2 | 1 | 2026 | Муниципаль милек | Дәүләт корпорациясе – Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды акчалары катнашында финанслана торган программа |
